**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«28» 07 2021 ел Яр Чаллы № 2048

Башкарма комитетның 2019 елның 5 июнендәге 2075 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр янымуниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даимийөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнарөлешен кире кайтару максатында,пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе»нә үзгәрешләр кертү турында

Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр янымуниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны йөртү белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Тукай муниципаль районы чикләрендә билгеләнгән транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 стаьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»887 номерлы карары, Тукай муниципаль берәмлеге уставы,Башкарма комитет Җитәкчесенең 2013 елның 22 маендагы «Административ регламентларны раслау турында» 2670 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 5 июнендәге 2075 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен кире

кайтарумаксатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен кире кайтару максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составы» 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (1кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 07 2048 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен кире кайтару максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин А.Р. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе–комиссия рәисе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Яббаров И.Н. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Игътисамов Р.С. | Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешентә эмин итү буенча урынбасары |
| Заһретдинов Ф.С | Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Халитова Э.А. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Бузина Н.К. | Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Лотфрахманова И.И. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Мадярова Д.Ә. | Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешентә эмин итү бүлеге баш белгече |
| Камалова А.Р. | Финанс-бюджет палатасының әйдәп баручы белгече. |